РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Урманаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Татарстан д.15«А»,, Азнакаевский район,
с.Урманаево, 423311,
тел./факс (885592)43-0-49
E-mail: Urman.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге
башкарма комитеты

Татарстан ур., йорт 15 “А”, йорт, Азнакай
районы, Урманай авылы, 423311
тел./факс (885592)43-0-49
E-mail: Urman.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » апрель 2022г. № 10

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елнын 18 февралендагы 05/76 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (31.03.2016 №07/28, 19.11.2016 №21/42, 04.09.2017 № 13/60, 11.07.2018 №18/102, 19.03.2019 №07/130, 19.02.2020 №02/158, 12.08.2021 №16/36 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Урманай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе 2022 елнын 11 апрелендәге бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең Урманай башкарма комитеты карар бирә:

1. Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елнын 18 февралендагы 05/76 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Урманай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең" җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә (31.03.2016 №07/28, 19.11.2016 №21/42, 04.09.2017 № 13/60, 11.07.2018 №18/102, 19.03.2019 №07/130, 19.02.2020 №02/158, 12.08.2021 №16/36 номерлы карарлар редакциясендә):

1.1. 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 3 статьясы һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясы белән туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый http://pravo.tatarstan.ruмәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: А.И.Закиров

Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитет карарына 1 нче кушымта №10 18.04.2022 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә керү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның II кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның II кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башлыгына “Урманай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Карар кабул итү өчен җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын авыл җирлеге Советына раслауга яисә кире кагуга һәм аны кабат эшләп бетерү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү. | III квартал 2022 ел |